Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында

бәяләмә

20.08.2025

Гавами тыңлаулар үткәрү урыны: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Байлангар ав., Совет ур., 6 й. (Байлангар авылы Мәдәният йорты бинасы).

Гавами тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты: 20 август, 2025 ел. 18 сәг. 00 минут.

Гавами тыңлаулар үткәрү инициаторы: Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге башлыгы

Гавами тыңлаулар уздыру өчен нигез: «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге составына керә торган Сазтамак тимер юл разъезды поселогын бетерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында» Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 7 августындагы 2 номерлы карары.

Гавами тыңлауларда каралган мәсьәләнең исеме: Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге составына керә торган Сазтамак тимер юл разъезды поселогын бетерү

Гавами тыңлаулар турында халыкка хәбәр итү: Гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүмати хәбәр (Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 7 августындагы 2 номерлы карары):

- Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Байлангар авылы, Совет ур., 6 йорт, Сазтамак авылы, Ленин ур., 34а йорты, Нормабаш авылы, Вахитов ур., 31 йорт территорияләрендә урнашкан мәгълүмат стендларында, шулай ук «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы сайтында.

Гавами тыңлауларда катнашучылар саны турында белешмәләр: 26 кеше.

Гавами тыңлауларда каралган мәсьәлә буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегендә яшәүчеләрдән язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кермәде.

Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча карар кабул ителде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге составына керә торган Сазтамак тимер юл разъезды поселогын бетерүнре хупларга.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Советына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль

районының Байлангар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге составына керә торган Сазтамак тимер юл разъезды поселогы торак пунктын бетерүгә халык ризалыгын белдерергә тәкъдим итәргә.

Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Байлангар авылы, Совет ур., 6 йорт, Сазтамак авылы, Ленин ур., 34а йорты, Нормабаш авылы, Вахитов ур., 31 йорт территорияләрендә урнашкан мәгълүмат стендларында, шулай ук «Интернет»челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы сайтында бастырып чыгарылырга тиеш.

Байлангар авыл җирлеге башлыгы: И.Ф. Кәримуллин

ОГРН 1021607752814
ИНН 1623001621